КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 26 июль г.Казань № 652

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Транспорт чараларын махсуслаштырылган урынга күчерүне, аларны саклау, кире кайтаруны оештыру, күчерү һәм саклау хакын түләү турында» 2019 ел, 10 октябрь, 899 нчы карарына үзгәреш кертү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип тану хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Транспорт чараларын махсуслаштырылган урынга күчерүне, аларны саклау, кире кайтаруны оештыру, күчерү һәм саклау хакын түләү турында» 2019 ел, 10 октябрь, 899 нчы карарына, 1 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе (алга таба – учреждение) административ хокук бозулар турындагы эшләрне башкаруны тәэмин итү кысаларында транспорт чараларын махсуслаштырылган урынга күчерүне һәм саклауны оештыру буенча махсуслаштырылган учреждение булып тора;».

2. Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында төбәк әһәмиятендәге һәм муниципаль районара әһәмияттәге автомобиль юлларыннан һәм юл корылмаларыннан транспорт чаралары хәрәкәте вакытлыча, сезонлы чикләнгән чорда авыр йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чаралары сала торган зыянны каплау сыйфатында (автотранспорт чарасының тулы массасы яки күчәрләренең норматив авырлыклары арткан өчен), Татарстан Республикасында юл сервисы объектларын төбәк әһәмиятендәге һәм муниципаль районара әһәмияттәге

гомумфайдалану автомобиль юлларына тоташтырган, юл сервисы объектларын, мәгълүмат конструкцияләрен һәм күрсәткечләрен, инженерлык коммуникацияләрен һәм башка корылмаларны проектлауга, төзүгә, урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә техник шартлар биргән, бирелгән техник шартларның үтәлешен алга таба тикшерүдә торган, тоткарланган транспорт чарасын махсуслаштырылган урынга күчергән (тәяүбушату эшләрен кертеп) һәм тоткарланган транспорт чарасын махсуслаштырылган урынга күчерү вакытыннан махсуслаштырылган урыннан кире кайтару вакытына кадәр аны саклаган өчен алынган акчаны файдалану тәртибен раслау турында» 2005 ел, 11 апрель, 171 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гомумфайдалану автомобиль юлларыннан авыр йөк һәм зур күләмле йөк ташучы автомобиль транспорты хуҗаларыннан яки аннан файдаланучылардан салына торган зыянны компенсацияләү сыйфатында авырлык тикшерүе постларында автотранспорт чарасының тулы массасы яки күчәрләренең норматив авырлыклары арткан өчен, түләүле юллардан һәм юл объектларыннан үткән өчен, шулай ук тоткарланган транспорт чараларын автомобильләрне махсуслаштырылган вакытлыча куеп тору урыннарына илтеп куйган һәм саклаган өчен, Татарстан Республикасының юл өчен бүленгән полосалары һәм гомумфайдалану автомобиль юлларының юл буе полосалары чикләрендә, Татарстан Республикасы территориясеннән үтә торган федераль гомумфадалану автомобиль юлларының юл буе полосаларында юл сервисы объектларын, тышкы реклама чараларын һәм башка корылмаларны урнаштыруны килештергән өчен һәм бирелгән техник шартларның үтәлешен тикшерүдә торган өчен алынган түләүне файдалану тәртибен раслау турында» 2005 ел, 11 апрель, 171 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 14 май, 308 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гомумфайдалану автомобиль юлларыннан авыр йөк һәм зур күләмле йөк ташучы автомобиль транспорты хуҗаларыннан яки аннан файдаланучылардан салына торган зыянны компенсацияләү сыйфатында алынган, авырлык тикшерүе постларында автотранспорт чарасының тулы массасы яки күчәрләренең норматив авырлыклары арткан өчен, түләүле юллардан һәм юл объектларыннан үткән өчен, шулай ук тоткарланган транспорт чараларын автомобильләрне махсуслаштырылган вакытлыча куеп тору урыннарына илтеп куйган һәм саклаган өчен, Татарстан Республикасы гомумфайдалану автомобиль юлларының юл буе полосалары һәм юл өчен бүленгән полосалары чикләрендә, Татарстан Республикасы территориясеннән үтә торган федераль гомумфайдалану автомобиль юлларының юл буе полосаларында объектларны һәм башка корылмаларны урнаштыруны килештергән өчен һәм бирелгән техник шартларның үтәлешен тикшерүдә торган өчен алынган түләүне файдалану тәртибен раслау турында» 2005 ел, 11 апрель, 171 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 ел, 5 август, 566 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында төбәк әһәмиятендәге һәм муниципаль районара әһәмияттәге гомумфайдалану автомобиль юлларыннан һәм юл корылмаларыннан транспорт чаралары хәрәкәте вакытлыча, сезонлы чикләнгән чорда авыр йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чаралары сала торган зыянны каплау сыйфатында (автотранспорт чарасының тулы массасы яки күчәрләренең норматив авырлыклары арткан өчен), түләүле юллардан һәм

юл корылмаларыннан узган, Татарстан Республикасында юл сервисы объектларын төбәк әһәмиятендәге һәм муниципаль районара әһәмияттәге гомумфайдалану автомобиль юлларына тоташтырган, юл сервисы объектларын, мәгълүмат конструкцияләрен һәм күрсәткечләрен, инженерлык коммуни-кацияләрен һәм башка корылмаларны проектлауга, төзүгә, урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә техник шартлар биргән, бирелгән техник шартларның үтәлешен алга таба тикшерүдә тоткан өчен алынган акчаны файдалану тәртибен раслау турында» 2005 ел, 11 апрель, 171 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 9 октябрь, 898 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 6 июль, 552 нче карарындагы 2 пункты.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин